КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 август г.Казань № 590

Татарстан Республикасы көненә һәм Казан шәһәре көненә багышланган бәйрәм чаралары уздырганда Казан шәһәре чикләрендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2007 ел, 15 октябрь, 562 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында азсыешлы судноларда йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы көненә һәм Казан шәһәре көненә багышланган бәйрәм чаралары уздырганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 30 августында Казансу елгасының «Миллениум» күпереннән алып Киров дамбасына кадәр участокта азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен кертеп) 16 сәгать 00 минуттан алып 22 сәгать 30 минутка кадәр куллануны тыюны (алга таба – тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә ёщм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин